КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 сентябрь г.Казань № 937

2023 елга Татарстан Республикасы карамагындагы, «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле, интернатлы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2023 елга Татарстан Республикасы карамагындагы, «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле, интернатлы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

2023 елга Татарстан Республикасы карамагындагы, «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле, интернатлы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү күләменә һәм дәреслекләр белән тәэмин итүгә карата төзәтү коэффициентларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы, «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 ел, 23 сентябрь, 907 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы, «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 ел, 23 сентябрь, 907 нче карары белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы, «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле гомуми белем бирү оешмаларында төп

гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күләменә карата төзәтү коэффициентларына үзгәреш кертү хакында» 2022 ел, 28 февраль, 170 нче.

3. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 1 сентябрь, 937 нче
карары белән расланды

2023 елга Татарстан Республикасы карамагындагы,
«кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле, интернатлы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасының төре | Хезмәт күрсәтүдән файдаланучыларның категорияләре | Территориаль дислокациясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, 1 елга сум |
|---|---|---|---|
| «Кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле, интернатлы гомуми белем бирү оешмалары | интернатта яшәүче тәрбияләнүчеләр | шәһәр җирлеге | 172 719 |
| | | авыл җирлеге | 177 643 |
| | интернатта яшәми торган тәрбияләнүчеләр | шәһәр җирлеге | 81 909 |
| | | авыл җирлеге | 83 156 |

________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 1 сентябрь, 937 нче
карары белән расланды

2023 елга Татарстан Республикасы карамагындагы, «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус исемле, интернатлы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү күләменә һәм дәреслекләр белән тәэмин итүгә карата

ТӨЗӘТҮ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫ

| Т/с | Гомуми белем бирү оешмасының исеме | Төзәтү коэффициенты |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | «Советлар Союзы Герое Хәсән Заманов исемендәге Актаныш кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3,679507 |
| 2. | «Павел Алексеевич Карпов исемендәге Болгар кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3,085798 |
| 3. | «Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин исемендәге Бөгелмә кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3,321413 |
| 4. | «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов исемендәге Васильево кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 2,307286 |
| 5. | «К.С.Байкиев исемендәге Икшермә кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3,209414 |
| 6. | «Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов исемендәге 82 нче кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,465769 |
| 7. | «Советлар Союзы Герое Никита Кайманов исемендәге Кадет мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,464197 |
| 8. | «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3,120858 |
| 9. | «Советлар Союзы Герое Михаил Алексеевич Чирков исемендәге Кама Тамагы кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3,540536 |
| 10. | «Советлар Союзы Герое генерал-полковник Василий Николаевич Гордов исемендәге Минзәлә кадет интер- | 3,218343 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | нат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 11. | «Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Идел буе федераль округының Татарстан кадет корпусы» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 4,004961 |
| 12. | «Генерал-майор Владимир Аверкиевич Хапаев исемендәге Тәтеш кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3,359248 |
| 13. | «Советлар Союзы Герое И.Н.Конев исемендәге Чирмешән кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3,762681 |
| 14. | «Советлар Союзы Герое Сергей Евдокимович Кузьмин исемендәге Чистай кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 2,579944 |
| 15. | «Калкан» полиция кадет мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1,404833 |